DOI: 10.26907/2311-2042-2023-20-1-165-170

# IBRAGIM NURULLIN AS A SCIENTIST, CRITIC AND PROSE WRITER

**Rifa Fatrakhmanovna Kharrasova,**
the Union of Writers of the Republic of Tatarstan,
14 Mushtari Str., Kazan, 420012, Russian Federation,
rita.rahman@yandex.ru



**Nurullin Ibragim** (18.04.1923–1.07.1995) was a literary critic, writer and teacher. He was Candidate of Philology from 1953, Doctor of Philology (1968) and Professor (1970); he worked as an associate professor and professor in KSU (now KFU) from 1953. He was the winner of the G. Tukay State Prize of the Tatar ASSR (1982) and got the Ayaz Iskhaki Award in 1992. He was a Chevalier of First and Second Degree Orders of the Great Patriotic War and a member of the Writers' Union of the Republic of Tatarstan from 1957. His scientific research focused on history of literature, literary theory, criticism, literary works of Tukay and Iskhaki, and methodology of teaching Tatar literature in higher and secondary general education schools.

**Нуруллин Ибраһим Зиннәтулла улы** (18.04.1923 – 1.07.1995) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы һәм педагог.

И. Нуруллин 1953 елдан филол. фән. канд., филол. фән. докторы (1968), проф. (1970); 1953 елдан КДУда (хәзер: КФУ) доцент, профессор вазифаларын башкара. Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге (1982) һәм Гаяз Исхакый премиясе лауреаты (1992). Ул беренче һәм икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры.

1957 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Аның фәнни эшчәнлеге әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, тәнкыйть, Тукай, Исхакый гыйльмияте, югары һәм гомуми урта белем бирү мәктәпләрендә татар әдәбиятын укыту методикасы тармакларына карый.

**Нуруллин Ибрагим Зиннатуллович** (18.04.1923 – 1.07.1995) – литературовед, критик, писатель и педагог.

Кандидат филологических наук (1953), доктор филологических наук (1968), профессор (1970); с 1953 г. работал в КГУ (ныне К(П)ФУ) в должности доцента, профессора. Лауреат Государственной премии ТАССР имени Габдуллы Тукая (1982), имени Гаяза Исхаки (1992) Кавалер Ордена Великой Отечественной войны I и II степени.

С 1957 г. Член Союза писателей ТАССР.

В орбите его научных интересов история татарской литературы, теория литературы, творческое наследие Г. Тукая, Г. Исхаки, методика преподавания литературы в средних и высших учебных заведениях.

Ibragim Nurullin was born to a family of teachers in the former Simbirsk Province, now the Melekessky District of the Ulyanovsk Region, in the village called Borovka on April 18, 1923. The adult life of the future scientist started off quite successfully for that time. After graduating from the Malyklinsky seven-year school and the Melekessky high school, he entered the Kazan Fur Technical School in 1938, but due to the war outbreak, he volunteered for the frontline in Stalingrad

in October, 1941. Shortly after, he got wounded and was released from military service. I. Nurullin started teaching in the Borovka seven-year school in October, 1943, and began his literary activity publishing his first stories in “Sovet ədəbiyaty” journal. His passion for literature and dream of becoming a writer made him move to the capital, and in 1945, I. Nurullin became a student of Kazan State University (now: Kazan Federal University), the Department of Tatar Philology. The student, who would occasionally write shorts stories, earned recognition in literary and academic community by winning the Tukay’s and Stalin’s scholarships, by contributing his remarkable literary criticism to periodical press, and by publishing his article “Татар хикәяләре” (“Tatar Short Stories”) in “Новый мир” (“Novy Mir”) magazine. He continued his postgraduate studies at KSU (now: KFU) and devoted his life to literature and science. I. Nurullin, who grew from a Teaching Assistant to a Professor, worked in various departments of the University such as the Departments of Tatar, Russian, and Foreign Literatures.

Ibragim Nurullin presented his Ph.D. thesis on Tukay’s ideological and aesthetic views in December, 1953, and later, devoted his entire life to the studies of Tukay’s poetry [1]. The scholar thoroughly analyzed Tukay’s work, conducting comprehensive and deep research in the context of the poet’s time; he purposefully studied Tukay’s biography, his environment and ancestry, trying to collect and objectively interpret every bit of information about the poet. As a result, he passed down a huge amount of fundamental works that fully reveal Tukay’s personality and oeuvre to both academic society and in literature.

I. Nurullin got interested in Tukay’s art through his own short articles and experiments in writing. The scholar’s article “Tukainyң ədəbi parodiyalərе” (“Tukay’s Literary Parodies”) was published in 1948 and immediately won the attention of the literary and scientific community [2]. In that article, the scholar mentioned Tukay’s involvement in the struggle waged for the theoretical substantiation of the emerging new Tatar literature, related to the first Russian Revolution, with his reviews-feuilletons, articles, poems and especially the works of a humorous and satirical nature. He stated that the poet denounced those who attacked the principles of realism and populism, and those with harmful ideas in literature; that in his mission, he relied on the experience of the Tatar people and Russian literature in creating parodies while favoring socio-political motives. The scholar analyzed Tukay’s humor, satire, and, most of all, his parodies in terms of their content and form, and defined the features inherent in those literary and social forms. He came to the conclusion that Tukay was an artist who defended democratic idealism subjected to the principle of realism. In his “Tukai tənkyitendə realizm həm tipiklyk məs’ələlərе” (“Realism and Typicality in Tukay's Criticism”), Nurullin claimed that the poet saw realism not as a mechanical copy of a real life, but rather a reflection in the light coming from a certain thought, idea and worldview. The scholar showed that Tukay was far from considering a typical image as a set of abstract thoughts, he understood typicality as an organic union of generalization and individualization. [3].

In his numerous scientific works, I. Nurullin relied primarily on the legacy of Tukay and his contemporaries while discussing populism, realism, the social role of literature, the principles of literary criticism, the issues of form and content, the relationship of fiction and folk art, the interaction of national verbal arts and the aesthetics of the era; he approached the work of such great talents as F. Amirkhan, Sh. Kamala and A. Iskhaki in a comprehensive way, striving to reveal the ideological and aesthetic views of each as an integral system. I. Nurullin pointed out that the positive ideological and aesthetic traditions of nineteenth century literature, Tatar folk art and Russian classic literature played a decisive role in the development Tukay’s literary skills and the formation of early twentieth century literature.

I. Nurullin emphasized the importance of covering Tukay’s literary activity objectively, suggesting to move away from assessing his art only through ideological perspective of the early 1960s; he would revisit that thought many times later on. For example, in his article “Shagyir’ne өirənү yuөlynda” (1966) (“Researching the Poet’s Oeuvre”) the scholar opposed “the representation of the poet in beautiful clothes and makeup, without showing him in his true colors”, that is, he stated that one should not deviate from true scientific reliability and objectivity [4, p. 127]. In the book “Tukai iҗaty (Berenche rus inkyilaby chory)” (“Tukay’s Art (The First Russian Revolution Period)” (1964), the scholar showed the ideological and aesthetic views of the poet in close connection with the First Russian Revolution, the social movement, the poet’s living conditions, his environment and his acquired expertise, including his knowledge of literature [5]. He believed that in Tukay’s poetry of 1906–1907, populist principles

prevailed. His ideas were primarily associated with the development of socio-political and literary-aesthetic views, with a revolutionary-democratic interpretation of the social role of literature; along with the practical implementation of the principles of critical realism, he expressed a number of judgments in this creative direction. The critic noted that Tukay, in his lyrical poems, gradually moved away from a conventionally romantic style of the East and switched to the lyric experience of Russian poetry. In his article "Tukai estetikasy həm rus ədəbiyaty" (Tukai Aesthetics and Russian Literature), the scholar revealed the poet's connections with Krylov, Koltsov, Pushkin, Lermontov, etc. using concrete examples; he mentioned that Gogol's work played an important role in shaping Tukay's ideas about realism and claimed that the poet's ideological and aesthetic position was closest to Nekrasov's, who stood at the origins of revolutionary-democratic poetry, and that such critics as Belinsky, Chernyshevsky, Dobrolyubov and Pisarev also had an influence on Tukay [6].

I. Nurullin did not remain indifferent to the literature of his time. He was always interested in the works of A. Eniki, N. Isanbet, M. Amir, A. Rasikh, M. Magdeev, F. Husni, S. Battal and many other talented writers. He praised their success and criticized their flaws, regardless of their social status. The scholar dealt with the problems of literary thought and its successful implementation. His articles and uncompromising integrity were capable of turning the periodical press into a platform for disputes. The critic's works "Obrazlar dөn'yasynda" (1964) [7], "Realizm turynda" (1974) [8], "Tormysh həm səngat' chynlygy" (1983) [9] have become handbooks for scholars. With his publications in the magazines "Novyi mir", "Druzhba narodov", "Voprosy literatury", "Volga", he made the Russian speaking readers reflect on certain topics and brought Tatar science into a wide arena.

I. Nurullin was the main figure who played a key role in Ayaz Iskhaki's return to his homeland. From the 1980s, he did a great job collecting the writer's works and evaluating his place in the history of Tatar literature. He published dozens of articles about the writer, who spent his life in exile. The scholar placed Iskhaki next to his favorite Tukay, highly appreciating his role in the development of the Tatar people's self-awareness [10]. Some of I. Nurullin's journalistic articles, published in the periodicals of the nineties, revisited the past, reflecting on it. As if he knew that his life was coming to an end, he hastened to share the memories of his life. In them, I. Nurullin showed the changes that he experienced as a person and as a scholar. He continuously fought for scientific accuracy and justice of life, came up with the ideas and proposals concerning such topics as keeping literature within the framework of wholesomeness, awarding talented writers with prestigious prizes and titles, identifying and developing talents, and supporting individuals who served the country. I. Nurullin's articles, published in the periodical press, were often distinguished by their polemical intensity, solid ideological stance, and the desire to convey what he considered fair to the public consciousness. He never ignored his opponents' arguments, always trying to give a reasoned answer.

I. Nurullin was never fond of overusing general concepts in his academic articles, he preferred arguing, detailing, convincing the reader using various examples and using the power of words. Every sentence that came off his pen showed that the scholar was very confident expressing his views. The fact that the scientific legacy left by I. Nurullin is being quoted and referred to as a talking point during various discussions to this day, proves that his judgments will never become outdated, they reflect his excellent education, foresight and serious approach to scientific problems, while making sure that this name passes into a New age and remains in the readers' memories.

Ibragim Nurullin is known as a scholar who studied Tukay, Kamal, Amirkhan and Iskhaki. These titanic talents can be considered his literary and scientific mentors. They taught him straightforwardness, literary sharpness, power of thought and self-criticism, and turned him into a big personality. As a proof of his spiritual and mental connection with his predecessors, I. Nurullin's book, called "Gabdulla Tukay", was awarded the G. Tukay State Prize of the Republic of Tatarstan in 1982; for his contribution to bringing back the name of G. Iskhaki to the public eye, he became the winner of the literary prize named after G. Iskhaki in 1992.

During his work at the university, Ibragim Nurullin raised a large number of disciples; various dissertations that differ in depth of thought were written under his guidance. The scientist, who left an enormous number of literary works, is still a great mentor for modern young researchers.

Professor Emeritus, Doctor of Philology Ibragim Nurullin died on July 1, 1995 in Kazan and was buried there.

**References**

1. Nurullin, I. Z. (1953). *K voprosu o razvitii ideino-ehsteticheskikh i literaturno-kriticheskikh*

*vzglyadov Tukaya: avtoref. dis. k. filol. n.* [On the Development of the Ideological-Aesthetic and Literary-Critical Views of Tukay: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 15 p. (In Russian)

2. Nurullin, I. Z. (1953). *Tukainyң ədəbi parodiyaləre* [Tukay's Literary Parodies]. Sovet ədəbiyaty. No.1, pp. 108–114. (In Tatar)

3. Nurullin, I. Z. (1953). *Tukai tənkyitendə realizm həm tipiklyk məs'ələləre* [Issues of Realism and Typicality in Tukay's Criticism]. Sovet ədəbiyaty. No. 12, pp. 110 – 116. (In Tatar)

4. Nurullin, I. Z. (1966). *Shagyir'ne өirənү yulynda* [Researching the Poet's Oeuvre]. Kazan utlary. No. 3, pp. 120–127. (In Tatar)

5. Nurullin I. Z. (1964). *Tukai iҗ̧aty (Berenche rus revolyutsiyase chory)* [Tukay's Art (The First Russian Revolution Period)]. 111 p. Kazan, Kazan un-ty nəshr. (In Tatar)

6. Nurullin, I. Z. (1955). *Tukai ehstetikasy həm rus ədəbiyaty* [Tukay Aesthetics and Russian Literature]. Sovet ədəbiyaty. No. 6, pp. 102 – 111. (In Tatar)

7. Nurullin, I. Z. (1964). *Obrazlar dөn'yasynda: ədəbi tənkyit' məkaləlәre* [In the World of Images: Essays in Literary Criticism]. 142 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

8. Nurullin, I. Z. (1974). *Realizm turynda* [On Realism]. 93 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

9. Nurullin, I. Z. (1983). *Tormysh həm səngat' chynlygy: ədəbi tənkyit' məkaləlәre* [The Reality of Life and Art: Essays in Literary Criticism]. 192 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

10. Nurullin, I. (1990). *Tukai həm Gayaz Iskhakyi* [Tukay and Gayaz Iskhaky]. Tatarstan yash'ləre. 12 mai. (In Tatar)

11. Nurullin, I. Z. (1979). *Gabdulla Tukai* [Gabdulla Tukay]. 304 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

# ИБРАҺИМ ЗИННӘТ УЛЫ НУРУЛЛИН – ГАЛИМ, ТӘНКЫЙТЬЧЕ ҺӘМ ПРОЗАИК

**Рифә Фатхрахман кызы Харрасова**,
Татарстан Респуликасы Язучылар берлеге,
Россия, 420012, Казан ш., Мөштәри ур, 14 нче йорт,
rita.rahman@yandex.ru .

1923 елның 18 апрелендә элекке Сембер губернасы, хәзерге Ульяновск өлкәсе Мәләкәс районы Пәрәү авылында мөгаллимнәр гаиләсендә дөньяга килә. Булачак галимнең олы тормыш юлы үз чоры өчен шактый уңышлы башлана. Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы җидееллык һәм Мәләкәс урта мәктәпләрен тәмамлагач, ул 1938 елда Казан мех техникумына укырга керә, әмма, сугыш башлану сәбәпле, 1941 елның октябрендә үз теләге белән Сталинград фронтына китеп бара. Озак та узмый, ул бик каты яралана һәм хәрби хезмәттән азат ителә. И. Нуруллин 1943 елның октябреннән Пәрәү җидееллык мәктәбендә укыта башлый, иҗат эшенә керешә, "Совет әдәбияты" журналында тәүге хикәяләрен бастыра. Әдәбиятны көчле ярату һәм язучы булу теләге аны башкалага тарта, һәм И. Нуруллин 1945 елда Казан дәүләт университетының (хәзер: Казан федераль университеты) татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Тукай, Сталин степендияләре алган, вакытлы матбугатта тирән эчтәлекле әдәби тәнкыйть материаллары бастырган, "Новый мир" журналында "Татар хикәяләре" язмасы чыккан, үзе дә хикәяләр языштырган студент әдәби-фәнни җәмәгатьчелектә билгеле шәхескә әверелә. Ул КДУ (хәзер: КФУ) каршындагы аспирантурага калдырыла һәм тормышын әдәбият, фән белән бәйли. Ассистентлыктан профессор дәрәҗәсенә күтәрелгән И. Нуруллин университетның татар, рус, чит илләр әдәбияты кафедраларында хезмәт итә.

Ибраһим Нуруллин 1953 елның декабрендә Тукайның идея-эстетик карашларын чагылдырган кандидатлык диссертациясе яклый һәм алга таба шагыйрьне өйрәнүгә бөтен гомерен багышлый [1]. Галим Тукай иҗатын, заман биеклегеннән торып, фәнни дәрәҗәдә, комплекслы, тирәнтен тикшерә; тәрҗемәи хәлен, тирәлек-даирәсен, нәсел-нәсәбен максатчан өйрәнә, шагыйрьгә кагылышлы һәр фактны бөртекләп барларга, объектив шәрехләргә тырыша, шулар нәтиҗәсендә фәнгә дә, матур әдәбиятка да Тукай шәхесен, иҗатын булдыра алганча тормышчан чагылдырган күпсанлы фундаменталь хезмәтләр калдыра.

И. Нуруллин Тукай фәненә әдәби иҗат тәҗрибәләре, кече күләмле гыйльми мәкаләләре аша килә. Галимнең "Тукайның әдәби пародияләре" исемле язмасы 1948 елда дөнья

күрә һәм шунда ук әдәби-фәнни җәмәгатьчелек игътибарын яулый [2]. Анда галим Беренче рус инкыйлабына мөнәсәбәтле формалаша башлаган яңа татар әдәбиятын теоретик нигезләү көрәшенә Тукайның рецензия-фельетоннар, мәкаләләр, шигырьләр, бигрәк тә юмористик-сатирик рухтагы әсәрләр белән катнашуын әйтә. Алар ярдәмендә шагыйрьнең реализм һәм халыкчанлык принципларына һөҗүмчеләрне, әдәбиятта зарарлы идеяләр үткәрүчеләрне фаш итүен күрсәтә; бу юнәлештәге эшчәнлегендә ул татар халкының һәм рус әдәбиятының пародик әсәрләр иҗат итү тәҗрибәсенә таяна, иҗтимагый-политик мотивларга өстенлек бирә. Галим Тукайның юмор-сатирасын, нигездә, пародияләрен эчтәлек һәм форма ягыннан анализлый, аларның әдәби һәм иҗтимагый төрләренә хас үзенчәлекләрне билгели һәм, Тукай – реализм принцибына буйсындырылган тенденциозлыкны – демократик идеялелекне яклаучы рәссам дигән нәтиҗәгә килә. “Тукай тәнкыйтендә реализм һәм типиклык мәсьәләләре”ндә (1953) Нуруллин, шагыйрь реализмны, тормышны механик рәвештә генә күчереп алуда түгел, билгеле бер фикер, идея, дөньяга караш яктылыгында чагылдыруда күрә, дип белдерә. Галим Тукайның типик образны абстракт фикер җыелмасы итеп караудан ерак торуын, типиклыкны гомумилек белән индивидуальлекнең органик берлеге итеп аңлавын күрсәтә [3].

И. Нуруллин күпсанлы гыйльми хезмәтләрендә халыкчанлык, реализм, әдәбиятның иҗтимагый роле; әдәби тәнкыйть принциплары, форма һәм эчтәлек, матур әдәбият белән халык иҗаты арасындагы бәйләнешләр, милли сүз сәнгатьләренең үзара тәэсире, чор эстетикасы һ.б. турында сүз алып барганда, беренче чиратта, Тукай һәм аның замандашлары мирасына таяна, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Исхакый кебек зур талантларның иҗатына ул комплекслы якын килә, һәрберсенең идея-эстетик карашларын тулыканлы система буларак ачарга омтыла. И. Нуруллин Тукай каләме камилләшүдә, XX гасыр башы әдәбияты формалашуда XIX йөз әдәбиятындагы уңай идея-эстетик традицияләрнең, татар халык иҗаты һәм рус классик әдәбиятының хәлиткеч роль уйнаганлыгын күрсәтә.

И. Нуруллин инде 1960 еллар башында ук, Тукай иҗатын идеологик ноктадан бәяләүдән китеп, объектив яктырту мөһимлеген әйтә, алга таба бу турыда кат-кат искәртә. Мәсәлән, “Шагыйрьне өйрәнү юлында” (1966) язмасында галим “шагыйрьне үз төсендә күрсәтмичә, матур киендереп һәм грим сөртеп тәкъдим итүгә” каршы чыга, ягъни чын мәгънәсендәге фәннилектән, объективлыктан тайпылмаска кирәк дип белдерә [4, 127 б.]. “Тукай иҗаты (Беренче рус инкыйлабы чоры)” (1964) китабында галим шагыйрьнең идея-эстетик карашларын Беренче рус инкыйлабы, иҗтимагый хәрәкәт, каләм иясенең яшәү шартлары, тирәлеге, алган белеме, шул исәптән өйрәнгән әдәбиятлары белән тыгыз мөнәсәбәттә чагылдыра [5]. Ул, Тукайның 1906 – 1907 еллар поэзиясендә халыкчанлык принциплары җиңә, бу алга китеш барыннан да элек иҗтимагый-политик һәм әдәби-эстетик карашларының үсешенә, әдәбиятның иҗтимагый ролен революцион-демократик рухта аңлый башлавына бәйләнгән; критик реализм принципларын практик рәвештә тормышка ашыру белән бергә, әлеге иҗат юнәлешенә карата кайбер фикерләр дә әйтә башлый, дип саный. Тәнкыйтьче, Тукайның мәхәббәт лирикасында, көнчыгышның шартлы-романтик стиленнән арына барып, әкренләп рус поэзиясе тәҗрибәсенә йөз тотуын әйтә. “Тукай эстетикасы һәм рус әдәбияты” мәкаләсендә галим шагыйрьнең Крылов, Кольцов, Пушкин, Лермонтов һ.б. белән бәйләнешләрен тәгаен мисаллар ярдәмендә ача; Тукайның реализм турындагы фикерләренең формалашуында Гоголь иҗатының зур роль уйнавын күрсәтә; шагыйрьнең идея-эстетик позициясе революцион-демократик поэзиясенең башында торган Некрасовка аеруча якын, дип яза; Н. Белинский, Чернышевский, Добролюбов һәм Писарев кебек тәнкыйтьчеләрнең дә Тукайга тәэсирен билгели [6].

И. Нуруллин үз заманында чыккан әдәбиятка да битараф калмады. Ул Ә. Еники, Н. Исәнбәт, М. Әмир, А. Расих, М. Мәһдиев, Ф. Хөсни, С. Баттал һәм башка бик күп талантлы каләм ияләренең язганнарына һәрвакыт игътибарлы булды. Уңышларын мактады, кемлегенә карамастан, җитешсезлекләрен тәнкыйть утына алды. Галим әдәби уйланма, аны отышлы рәвештә тормышка ашыру проблемасын чишәргә тырышты. Аның язганнары, компромиссларга бара белмәгән намусы вакытлы матбугатны бәхәсләр мәйданына әвереллерергә сәләтле иде. Тәнкыйтьченең “Образлар дөньясында” (1964) [7], “Реализм турында” (1974) [8], “Тормыш һәм сәнгать чынлыгы” (1983) [9] хезмәтләре әдипләрнең өстәл китабына әверелде. Ул, “Новый мир”, “Дружба народов”, “Вопросы литературы”, “Волга” журналларында басылган

язмалары белән, рус укучысын да уйга салды, татар фәнен киң мәйданга алып чыгарга тырышты.

И. Нуруллин Гаяз Исхакыйның илгә әйләнеп кайтуында төп рольне уйнаган кеше иде. Узган гасырның сиксәненче елларыннан ул әдип иҗатын барлау, бәяләү, аның татар әдәбияты тарихында тоткан урынын күрсәтү юлында зур эшләр башкарды, гомере мөһаҗирлектә узган әдип хакында дистәләрчә мәкалә бастырды. Галим Исхакыйны үзе яраткан Тукай янәшәсенә дә куеп карады, икесенең дә татарның үзаңын үстерүдәге роленә югары бәя бирде [10]. И. Нуруллинның туксанынчы елларда вакытлы матбугатта дөнья күргән кайбер публицистик язмалары, узганга кайтып, тагын бер кат уйланулар рухында иде. Гомеренең ахырына җитеп килгәнен белгәндәй, ул үз күңелендә сакланган истәлекләр белән уртаклашырга ашыкты. И. Нуруллин аларда үзенең шәхес һәм галим буларак кичергән үсеш-үзгәрешләрен дә күрсәтте. Ул һаман да фәнни төгәллек һәм тормыш гаделлеге өчен көрәште, әдәбиятны камиллек кысаларында тоту, каләм ияләренә дәрәҗәле бүләк-исемәрне лаек бирү, талантларны күреп алу һәм үстерү, илгә хезмәт иткән шәхесләрне пропагандалауга мөнәсәбәтле фикер-тәкъдимнәр белән чыгыш ясады. И. Нуруллинның вакытлы матбугатта дөнья күргән мәкаләләре еш кына полемик накал, гражданлык позициясенең ныклыгы, гадел санаган фикерләрен җәмәгатьчелек аңына уздыру омтылышы белән аерылып тора иде. Ул бервакытта да оппонентлары белән бәхәсләрдән читкә тайпылмады, дәлилле җавап бирергә тырышты.

И. Нуруллин фәнни хезмәтләрендә гомуми сүзләр белән мавыкмады, дәлилләүне, тәфсилләүне, укучыны төрле мисаллар һәм шул ук вакытта сүз көче ярдәмендә дә инандыруны хуп күрде. Аның каләменнән чыккан һәр җөмлә галимнең үз-үзенә бик нык ышанып язганлыгын сөйли. И. Нуруллин калдырган фәнни мирасның хәзергәчә кулланышта йөрүе, фикерләренең искермәве, теге яки бу бәхәсләр вакытында аргумент сыйфатында китерелүе аның тирән белемлелеген, алдан күрүчәнлеген, фәнни проблемаларга җитди якын килүен чагылдыра һәм бер үк вакытта бу исемнең яңа чорларга күчүенә, укучы хәтерендә яшәвенә дә хезмәт итә.

Ибраһим Нуруллин тукайчы, камалчы, әмирханчы, исхакыйчы буларак танылды. Әлеге титаник талантларны аның әдәби-гыйльми остазлары дип санарга мөмкин. Ул алардан турысүзлелеккә, каләм үткенлегенә, фикер көченә, үз-үзенә таләпчәнлеккә өйрәнгән олы шәхес иде. Галим белән үзеннән элгәреләрнең рухи-фикри бәйләнешләрен раслагандай, 1982 елда И. Нуруллинның “Габдулла Тукай” исемле китабы [11] Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бәяләнде, ә Г. Исхакый исемен җәмәгатьчелеккә кайтару юлындагы хезмәтләре өчен 1992 елда ул Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе булды.

Ибраһим Нуруллин университетта укыту дәверендә күпсанлы укучылар тәрбияләде, аның җитәкчелегендә фикер тирәнлеге белән аерылып торган диссертацияләр язылды. Күпсанлы хезмәтләр калдырган галим – бүгенге яшь фәнни эзләнүчеләр өчен дә зур остаз.

Мөхтәрәм профессор, филология фәннәре докторы Ибраһим Нуруллин 1995 елның беренче июлендә Казанда вафат булды һәм җирләнде.

**Әдәбият**


1. Нуруллин И.З. К вопросу о развитии идейно-эстетических и литературно-критических взглядов Тукая: автореф. дис. ... к. филол. н. Казань, 1953. 15 с.
2. Нуруллин И.З. Тукайның әдәби пародияләре // Совет әдәбияты. 1953. №1. Б. 108 – 114.
3. Нуруллин И.З. Тукай тәнкыйтендә реализм һәм типиклык мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1953. №12. Б. 110 – 116.
4. Нуруллин И.З. Шагыйрьне өйрәнү юлында // Казан утлары. 1966. №3. Б. 120 - 127 б.
5. Нуруллин И.З. Тукай иҗаты (Беренче рус революциясе чоры). Казан: Казан ун-ты нәшр., 1964. 111 б.
6. Нуруллин И.З. Тукай эстетикасы һәм рус әдәбияты // Совет әдәбияты. 1955. №6. Б. 102 – 111.
7. Нуруллин И.З. Образлар дөньясында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 1964. 142 б.
8. Нуруллин И. З. Реализм турында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 93 б.
9. Нуруллин И.З. Тормыш һәм сәнгать чынлыгы: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 192 б.
10. Нуруллин И. Тукай һәм Гаяз Исхакый // Татарстан яшьләре. 1990. 12 май.
11. Нуруллин И.З. Габдулла Тукай. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 304 б.